*Бу дөньяда бөтен нәрсә үзгәрүчән,*
*Бу дөньяда бөтен нәрсә үзгәрүдә,*
*Бу дөньяда һәрнәрсәнең башланмышы,*
*Дәвамы бар, һәм ахыры, дөнья очы.*

*Һәммә нәрсә фани, фани барча дөнья,*
*Бакыйлыкка дәгъва кылган меңнәр кайда?*
*Тик мәңгелек алда булыр, булган элек...*
*Бу парадокс – дөнья фани ...һәм мәңгелек*

***Сөләйман***

СӨЛӘЙМАН
*Каталун дәфтәреннән*

# СӨЛӘЙМАН

## Каталун дәфтәреннән

# СӨЛӘЙМАН

## Каталун дәфтәреннән

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)6-5
С98

**Сөләйман, Җ.Ш.**
**С98** Каталун дәфтәреннән / Сөләйман – Казан: ТР Фәннәр академиясе нәшрияты, 2017. – 116 с.

ISBN 978-5-9690-0371-2

Язмыш шагыйрь Сөләйманны, көтмәгәндә-уйламаганда, Испан иленең иң матур бер төбәге булган Каталуниягә китереп, күңел җилкәнен Урта диңгез җилләренә тутырып ачарга мөмкинлек бирә. Шагыйрьнең фани дөнья һәм мәңгелек, җан һәм бәгырь, адәм һәм җиһан, нәсел җепләре һәм яшәү мәгънәсе хакындагы хис-фикерләре, кайчандыр шул җирлектә, Урта диңгез буенда яшәп, тарихта югалган готлар-котлар, кәлтә-кельт, барс токымнары, һуннар турында уйланулары, сагынулары – барысы да Каталун дәфтәре булып санак хәтеренә язылып бара...

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)6-5

**ISBN 978-5-9690-0371-2**

© Сөләйман Җ.Ш., 2017
© ТРФА нәшрияты, 2017

***

Урал таулары, Идел буйлары,
Яшәсен татар балалары...

*(Фәрит Агиның* мөһәҗирләр җырын башкаруын тыңлаганда)*

Бавар иле. Мюнхен. Кич утыру.
Татар җырын суза Фәрит абый.
Татар моңы Бавар мохитендә –
Бәгырьләрне бәгырьләргә ялгый.
Җыр яңарта безнең күңелләрдә
Идел-Урал җирен, хыялларны.
Татар җырын суза Фәрит абый,
Яшәсен, дип, татар балалары!

*9 ноябрь 2015*

** Фәрит Аги – чит илдә туып-яшәп, күп еллар “Азатлык” радиосын җитәкләгән милләтпәрвар*

***

Барс илендә, Барс җирендә,
Барселона – нәкъ Биләр!
Болгарлар атлар уйнаткан,
Болгар яшәгән җирләр.
Монда мин дә кунак түгел,
Юл ятса да ерактан,
Котым белән тоям шуны –
Бу – борынгы өй-хатам...

*21 декабрь, 2017*

***

Дөньяның төрлелегенә
ышандыра Барс иле,
Дөньяның бердәйлегенә
ышандыра Барс иле.
Дөньяларның күплегенә
ышандыра Барс иле,
Ә бит дөнья кайда да бер
дигән чаклар бар иде.

Бер карасаң, бар да башка,
үз килбәтле Барс иле,
Барысы да бер килбәт дип,
уйланган чак бар инде...

*22 декабрь, 2015*

***

Җир шарында
 шундый киңлек,
Шундый муллык кайда да,
Килер заман, нигез корыр
Адәми зат
 ...айда да.
Туган җиреӊ казык булса,
Булсын казык – нигезгә,
Сине бәйләп тоткан казык –
Тышау белән тигез лә!
Казык кактыӊ, йорт-җир кордыӊ,
Инде күр йолдызларны,
Зәмәттән* ары дөнья бар –
Тышаудан гына арын!

*22 декабрь, 2015*

** зәмәт (миш.) – койма*

## Тел дөньясы

Тел дөньясы – төпсез дәрья,
Тел дәрьясын сөзәм димә,
Сөзү түгел, йөзә алыр
Йөзү рәтен белгән генә.
Фонемалар, морфемалар –
Мәгънәлеләр, мәгънәсезләр,
Тулыр-тулмас җөмлә булып
Пешәр-пешмәс төшкән сүзләр...

Адәмнәрдән түгел дөнья,
Шул сүзләрдән, җөмләләрдән,
Кешеләр дә, халыклар да
Кием генә шул сүзләргә.

Адәми зат телләр өчен
Көй чыгаргыч бер уйнаткыч,
Бу шигырьне шигырь димә,
Уйлан, адәм, бу – уйлаткыч...

*22 декабрь, 2015*
*Каталуния мәйданы,*

***

Бер карыйсың,
кеше – алма корты,
Җир-алманы казый адәм
көне-төне,
Тамак колы, нәфес колы адәм,
Җир үзәген телә
телем-телем...
Бер карыйсың, адәм – күбәләктәй,
Аллы-гөлле күңел канатлары,
Моңга манма җир-болын да
моңсу булыр иде
Күбәләксез калып...
Бер карыйсың,
адәм – иң бөек зат,
Аллаһ биргән зиһен, акыл-фәһем...
...Тамак туяр, канат ныгыр, акыл артыр –
Адәм иткән рух кылларың өзелмәсен...

*23 декабрь, 2015*

***

Хәтер җебе тоташ
    ундүрт буын буе,
Тармак-тармак –
    кайда – урман, кайда – кое...
Шәҗәрәдә гасырлардан килгән сурәт –
Зур бер нәсел, бер кабилә, олы өммәт.

Ундүрт буын җанлы хәтер, җанлы сурәт,
Өзелмәс бер чылбыр булып
    килә рәт-рәт,
Буыннарга мине бәйли ошбу рәсем,
Шәҗәрәне дәвам итә
Яңа исем,
Тимур улы Әлмир хәзер рәсем чугы,
Нәсел – җәя,
Очлы ук бул Син, оныгым!

*23 декабрь,2015*

***

Кемгә дә бәйләнмим,
Уйланам үземнән,
Кемнәрне
    хәтерлим
Нәсел-җеп эзеннән?

Буыннар тирәннән,
Тезелгән исемнәр,
Шулардан кайсысы
Якыннан исемдә?

Уйлансаң –
    бар сәбәп,
Бик кыска хәтерләр,
Буыннар тоташтан -
Күпмесе хәтердә?..

*24 декабрь, 2015*

## Татарга

Татар теле дигәч,
күз алдында -
чырага телгәләнгән агач...

...татар телен кара -
күз алдында,
каурыйларга таркалган канат...

...татар теле исән,
әмма, дөрес,
өзгәләнгән аркандыр дисәң...

...татар теле хәле
авыр дип сыкранып,
ни кылдың соң әле?..

*30 декабрь, 2015*

***

Бер карыйсың,
адәм көчле, үзе – Алла,
Ул:  бул! дисә,
меңләп шәһәр, дөнья туа,
Адәм кодрәтеннән урман гөрләп үсә,
Адәм эзен ерак айдан табып була...
Бер карыйсың –
адәм үзе – ком бөртеге,
Чиксез җиһан киңлегендә бармы? юкмы?
Ком бөртеге дию – хәтта үстерүдер,
Күктән караганда адәм – барлы-юклы...
Ничек карап күренә соң, адәм-бахыр? -
Караганда мин-минлеге күзлегеннән,
Үз үлчәмен җайлап җирдән-өскә таба,
Йолдыз булып ут чәчкәндә ...үз күгендә.
Адәм җирдә иң зиһенле, акыллысы,
Һәр адәмдә, имеш, Аллаһ  чагылышы,
Җиһандагы җанлы, җансыз җисем-затлар
иң бөек зат – адәм өчен,
Аллаһ кушып...
Берсен-берсе тукмап-тетеп, ватып-сүтеп,
Куәт-ләззәт тоя адәм – ул бер гигант!
...Бу мизгелдә  югарыдан аска кара -
Микроблардан ни аерман, адәми зат?
...Мин үзем дә шул ук адәм,
Тыпырчынам Җир-ятьмәдә, өзгәләнеп, җавап эзләп,
Серләр сүтәм, янә ялгыйм, кисәм, тегәм,
Энә-фикерләргә сүзләр саплап-күзләп...

*8 январь, 2016*

***

*Диңгездән кайтканда*

Күңел-диңгез төпкелендә
Ниләр барын кем белә,
Төсмерләсәң – төсмерләрсең,
Бары бер үзең генә.
Күңел-диңгез төпләренә
Сирәкләр төшә белә,
Сиңа гына ачылыр сер
Тирәндә яши бирә...
Һәр күңелнең үз ачкычы,
Күңел тулы бүлмәләр,
Бүлмәләргә керсә – керер
Көен-җаен белгәннәр...

*10 январь, 2016*

***

Диңгез буе. Дулкын уйный,
Гүяки, бәргәләнә,
Шул чакларда күңел түзми,
Талпына, өзгәләнә.
Җилкәнгә тулган җилләрдәй
Күңел тулы сагыну...
... Минутлык хис –
тиз тарала
...диңгез җиле кагылып.

*16 январь, 2016*

***

Адәмдә өч дөнья – береккән өч фәза*,
Нәфесе – нигезе. Канаты – рух-наза**.
Өченче дөньясы – фәһеме-акылы***.
Нечкә тән сузылган өч дөнья аркылы.
Бер итеп, бар итеп, сүр**** тота адәмне,
Көмештән тегелгән нечкә тән киеме.
Сүр-сүрә сүзендә мишәрнең “цүрәсе”,
Киемнең аслыгы,нәфеснең эргәсе*****.
Сер түгел – көт тә тор гомерең сүнәсен,
Сүрелсә, таркалса, тәнеңнең чүрәсе******...

*16 январь, 2016*

** фәза – пространство (рус.)*
*** наза – кешенең рух тәнен төзүче тибрәнешләр (җыр-көйләр, рәсем һ.б.)*
**** фәһем (гарәп теле аша кайткан сүз) – интеллект. Минемчә, татар телендә русның “мудрость” сүзе мәгънәсендә куллану отышлы*
***** сүр – физик тәннең нигезе, матрицасы, калыбы (шуннан “сүрәт” – образ сүзе)*
****** эргә – нигез (фундамент)*
******* чүрәсе – эчке ягы (рус.: изнанка)*

***

Күзне йомсам – Аккош күле*,
Ап-ак дөнья, кар-буран,
Күзем ачсам, Урта диңгез -
Бер – өнем, бер – төш сыман.

Күзне йомсам – җылы хисләр –
Нурлы Казан күңелдә,
Күзем ачсам – кояш балкый –
Барселона күгендә.

Күзне йомсам, Аккошта – кыш,
Зәмһәрир суыклары...
Күзем ачсам – яшел пальма,
“Монах” тутый кошлары...

Бер йомам да бер ачамын
Күзләрне, шулай итеп,
Истәлекләр җылысында
Сагышларны эретеп.

*18 январь, 2016*

** Аккош күле – татар язучыларының иҗат йортлары урнашкан бакча*

***

Каталуния илендә
Кырыс холыклы халык,
Кот оланын җиңел генә
Булмый сыртына салып.
Кот уллары ирек даулый,
Яратмый тышаулауны,
Иделдә дә, диңгездә дә
Бер халык ...тере канлы!

*8 февраль, 2016*

***

Иртәгә футбол уены –
Барслар белән Кәлтәләр*,
Төрки дөньяга киная
Бу хикмәтле нәрсәләр.

Дистә мең еллар элек тә
Булган шундый уеннар,
Төрки өммәт гомер сөргән
Урта диңгез буенда.

Шул чаклардан Барс өммәте,
Кәлтә-кельтлар шул чордан...
Нинди давыл шул тарихның
Көлен җилгә очырган?!

*8 февраль, 2016*

** Барселонада "Barsa" (Барс) һәм "Celtik" (Кельт – Кәлтә) командалары арасында футбол уены уңаеннан шигырь-уйлану*

***

Барселона, Барселона,
Ай йөзә төнге күктә,
Әллә шулмы сагынулар –
Күңел тула кич-иртә.
Барселона һич йокламый,
Көнме-төнме – мәш килә,
Шәһәр кайда да шәһәр дә,
Йокы татлырак өйдә...

*11 февраль, 2016*

***

Барселона, Барселона,
Нәрсәң артык Казаннан?
Табигатең, дияр идем,
Җир-суга бай Казан да.
Халкың белән, дияр идем,
Халык төрле бездә дә,
Холкың белән, дияр идем,
Холык һәммәбездә дә.
Шул ук ай күктән елмая,
Болытлар шул рәвешле...
Тик ...башка сыман, нигәдер,
Монда дөнья рәвеше...

*11 февраль, 2016*

***

Уңнан-сулдан машиналар,
Уңнан-сулдан кешеләр...
Мин бер чатта, мин бер фәкыйрь,
Меңләп минем ишеләр.
Мин бу чатта вакытлыча,
Мин бу чатта көч җыям,
Барселона һавасында
Диңгез сулышын тоям.
Мин биредә вакытлыча,
Барселона, бир көчең!
Диңгез җилләрен иярлим,
Иделдә җигәр өчен...

*11 февраль, 2016*

***

Барселона бүген моңсу,
Яңгыр юган урамнарын.
Зәйтүн мае сылагандай
Өсләренә таш сыннарның.
Күк болытлы. Күңел – уйчан.
Борчулар юк – яңгыр юган.
Кояш та юк, әмма якты
Бер-береңә елмаюдан.
Бер кафеда. Җылы. Тыныч.
Фикерләргә монда – ирек.
Ә Әнисә, кошчыгыбыз,
Йоклый шунда, төшләр күреп...

*11 февраль, 2016*

***

Учак янында гәпләшү –
Мәңгелек тә, чиксезлек...
Хакыйкать, дип, мәхәббәт, дип,
Дәлилләр сиптек, тездек...
Ул кызулар, җилпенүләр,
Гайрәтне гайрәт чапты...
Ә безнең тормыш, уйласаң,
Учактан очкан чаткы...

*12 февраль, 2016*

***

*Готик кварталда (готлар бистәсендә) йөргәндә*

Готик квартал дигәннәре –
Готлар-котлар* бистәсе,
Каталуннар – кот оланнар
Шулай калдырган эзен.
Гаудига** монда да урын
Бирелгән зурдан кубып,
Каталун данын күтәргән
Мәшһүр кот халкы улы...
Котлар бистәсе билгесе –
Таштан текә биналар,
Иңгә-иң баскан гаскәрдәй
Ядрә сыймас аралар.

Кот оланнар җиңелмәгән,
Үзгәртсә дә кимәлен,
Каталуннар булып яши
Бүген ул көчле кавем.

*15 февраль, 2016*

,

** Готлар-Котлар – Көнчыгыш Европада б.э. II – VIII гасырларында яшәгән халык. Төрки-татарча кот – җан-рух төшенчәләрендә кулланыла (котым очты, җаным очты, котсыз – рухсыз). Кот сүзе диалектта гот булып яңгыраш тапкан, шуннан Got (алманча)- God (Инглизчә) – Алла сүзләре-төшенчәсе ясалган дип фаразларга мөмкин*
***Гауди – танылган Каталун архитекторы*

***

Гренаданың Испан моңсулыгы
Күптән инде күчкән җырларга,
Я, кем генә “минем Гранадам”, дип,
Сиңа атап җырлар язмаган.
Ә тауларың – үзе җыр тезмәсе,
Башларында кардан ак калфак,
Үзе шигырь синең гүзәллегең,
Фигылеңдә синең – хәер-хак...

*19 февраль, 2016*

## Фламенко

Яңгыр итәкле фламенко,
Тамчы-тамчы – үкчәләр,
И кыздыра яз яңгыры,
Чәчри
    утлы
        тәңкәләр!
Кояш нурлары чагыла
Йөгерек тамчыларда,
Чәчрәп сибелгән тамчылар
Ал, көмеш очкыннардай!
Гранадада яз яңгыры,
Язның канат кагуы...
Яңгыр итәкле фламенко
Тишкәли кыш чабуын...

*20 февраль, 2016*

***

Бу – Гранада, күпне күргән шәһәр,
Бишек булган шәһәр күпләргә.
Бер күтәргән күккә, я шунда ук,
Җиргә аткан йолып күкләрдән.
Бөек Лорка* шул бишектә үскән,
Шул бишектә күккә чөелгән,
Шигырьләре
        бер – янартау булган,
Бер – көл тавы булып өелгән.
Үлем белән яшәү арасында
үзе бишек булган Лоркага
сөю-көю, яну-сүнү – гадәт!
Ә син аңла йөрәк, син – чыда!

Гранадада. Таулы урамнарда
тоям сыман Лорка эзләрен,
Урам очындагы кыя-таулар
сеңдергәндер сыман сүзләрен...
Бу шәһәрнең Лорка – бер гасабы,
Шигырьләре – йөрәк тибеше...
Рәхмәт язмыш, миңа бу зур бүләк -
Шагыйрь Лорка белән күрешү...

*20 февраль, 2016*

** Испан шагыйре Гарсиа Лорка*

## Альгамбра*

Язын, җәен гөлләр патшалыгы,
Гранаданың затлы йөзек кашы,
Аһ, Альгамбра, син гүзәлне күрү
Чынлап рәхәт икән хәтта кышын!
Таш челтәрдән тәрәз пәрдәләре,
Таш чигүле дивар-түшәмнәре,
Алла сүзен яңгырата сыман,
Чигү булып, сырлы хәрефләре.
Челтәр-челтәр таш бизәкләр аша
Кояш керә ап-ак шәмнәр  булып,
Челтәр күзләреннән үтә нурлар
Йөрәкләргә, бүлмәләргә тулып.
Чал Альгамбра, көлдән гөл булгансың,
Мең еллык зар синең ташларыңда,
Гранадага алтын казык булып
Кагылгансың син тау башларында.
Зәңгәр күккә көмеш уклар чөеп,
Чәчрәп каршы чыга фонтаннары,
Көй-моңнары сеңгән бүлмәләре
Сагына сыман әле солтаннарын.
Уд-гөслигә татлы моңын кушкан
Көмеш кыллы җитез кәмәнгәләр**,
Канун-арфа кылларына чиртеп
Хан күңелен күргән җарияләр.
Хәтерләтеп безнең курай моңын,
Най кушылган көйләр агышына,
Таңнары да уянгандыр сыман
Чут-чут килгән кошлар тавышына.

Аһ, Альгамбра, язын, җәен, кышын,
Күрдем сине төрле халәтеңдә,
Сиңа карап күзалларга була
Гөл-җимешле бакча – җәннәтне дә...

** Гранадада гарәпләр төзегән кирмән-шәһәр*
*** кәмәнгә (скрипканың бер төре), канун (цитра-арфага ошаган инструмент), уд (гөсли формасы), най (флейта, курай кебек) – борынгы уен кораллары*

*20 февраль, 2016*

***

Гарәптән калган дисәм дә,
дөрес булмас, калмаган,
Гарәп каны, гарәп халкы
китмәгән, югалмаган.
Кибеткә кибет ябышкан,
Гөл белән дөнья тулган.
Гранадага чәй исләре
тарала Альбайсиннан.
Бу бистәнең урамнары,
тарих арбасы сыман,
Кайтарды мине гарәпләр
гөрләп яшәгән чорга.
Төпкә төшеп казынмасаң,
Бер карашка әле дә,
Бу бистәдә шул ук халык
гөрләп торган хәлендә!

*20 февраль, 2016*

***

Без биредә икәү, шуңадыр, җан тыныч,
Агачларда алтын әфлисуннар,
Бергә булгач, шулай, дөнья да башкарак -
Елмайгандай хәтта безгә сыннар.

Бергә чакта безгә этләр дә өрмиләр,
Койрык болгый кебек, сәлам биреп,
Шуны тоеп чәйләп утырабыз икәү,
Уртак гомер, уртак күңел, бер җан кебек...

*21 февраль, 2016*

***

Альборрея, Альбохарра* –
Кайда да гарәп сүзе,
Йөзләп гасырлар үтсә дә,
Сакланган гарәп эзе.
Тауга яткан урамнарда
Тарих калган ягылып –
Тоташып киткән йортларда
Күрәм гарәп чалымын.

Андалусия җирендә,
Бәхәс юк, Испан халкы,
Әмма тирән сеңгән сыман
Гәрәп чырае, холкы.
Шуннандырмы, кунакчыллык,
Йомшак күңел, ачык йөз,
Кан катнашы, җан катнашы –
Тәңредән килгән нигез...

*22 февраль, 2016*

** Гранада шәһәрендәге бистәләр*

***

Дөнья якты, әмма – кысан!
Лоркамы түзсен шуңа!
Юк тынгылык, йөрәк ярсый,
Күңел күккә атыла!
Таш диварлар аңа кысан –
Кая инде ул түзү!
Таштан ташка бәргәләнә
Лорканың утлы сүзе!
Бу язмыштан юк котылу,
Лоркага юл салынган,
Кыргый байтал – бәйсез ирек! –
Аның кайнар канында!

Бу юлның чиге билгеле,
Бу юлның чиге – упкын,
Шул упкынга оча Лорка,
Этәрә байтал холкы!..

*23 февраль, 2016*

***

Шәһәр ап-ак
   кояш кызуында,
Яктылыкка күмелгәндәй гөлләр,
Яктылыктан кара тасма кисеп,
Куаклардан төшә күләгәләр.
Бер үк кояш күктә бар дөньяга,
Тик, нигәдер, монда ул эссерәк,
Гранадада сиеста кызуы,
Чәчкә-яфрак йоклый, әлсерәп...

*23 февраль, 2016*

***

*Әни белән телефоннан сөйләшеп алгач...*

«Бер кар ява ишеп, буран дулый,
Яңгыр явып үтә шулар арасында”,
...Бу – безнең ил, монда безнең тормыш,
Иле кебек, халкы кебек һавасы да...

Табигатьнең үз дөресе – дөрес,
Син табигать кызы, беләсеңдер, әни.
Ил – бүген ил, халык та үзгәрә...
Син һаман яшь, әни,
син бар, син бер – әни!..

*23 февраль, 2016*

***

Ап-ак тешле Невада пычкысы*,
Болытларны тишеп, күккә тигән,
Кулны сузсаң, уч төбендә кебек,
Менәм дисәң, менеп җитәм, димә.
Колачарын җәйгән Алып сыман,
Гранаданы алган кочагына,
Ә Гранада урам-толымнарын
Сузган сыман, уйнап, тау ягына.
Толымнарда – сары әфлисуннар.
Үрелгәннәр яшел тасма белән...
Бу мизгелләр – Ходай бәрәкәте
Keләүләргә** тулы күңелемә.

*25 февраль, 2016*

** Сьерра-Невада – тау исеме. Сьерра – испанчадан: пычкы*
*** keләү – Аллага ялвару*

***

Кулда каләм, ак бит кәгазь,
Язасы да, язасы,
Күңелгә – җим,
Аңга – ризык,
Тәнгә – дәрман саласы,
Кыл тибрәтеп аласы.

Кулда каләм, ак бит кәгазь,
Чакма белән чакматаш.
Каләм кәгазьгә тигәндә
Мин үзем утка охшаш,
Мин үзем уттан, тоташ.

Каләм сыза ак кәгазьгә
Ташып чыккан хисләрне,
Кояш нурлары җылыта
Каләм сызган битләрне,
Шигырь яткан битләрне...

*25 февраль, 2016*

***

Чал Альгамбра итәгендә,
Кояш тулы Яңа мәйдан,
Февраль бүген. Әмма рәхәт.
Аерып булмас безнең майдан.
Кара кофе. Ак салфетка.
Чыр-чу килеп, кызлар үтә...
Кайнап, бәреп чыгар өчен,
Шигъри хискә шул да җитә...

*25 февраль, 2016*

***

Моннан карап – Казан тимерчелек,
Чаң-чоң суга чүкеч зур сандалга,
Көлтә-көлтә чаткы, ә карасаң –
...һава изә чүкеч шул сандалда.
Күрек булып ...халык үзе өрә,
Тынын биреп утлы күмерләргә,
Һава кыза – ...сыңар дага да юк,
Инде сүнеп барган күмерләрдә.
Тимерченең кулы-кулга йокмый,
Күз иярми авыр чүкеченә,
Бөтен дөнья тимерчелек кебек
Кара тиргә баткан тимерчегә.

...Моннан карап Казан – тимерчелек...

*25 февраль, 2016*

***

Лорка йорты. Лорка йөргән бакча.
Җанга рәхәт бирә бу рәсем.
Аңым белән иңлим, кабул итәм,
Күңелем белән килә тоясым.
...Дали учагының чаткылары
Шагыйрь йөрәгендә дөрләгән,
Кырыс Мадрид ике даһи юлын
Утлы төен итеп бәйләгән...
Аң сыйдыра. Күңел дә үз итә.
Шигъри җанын. Агын-карасын.
Әмма ничек җанга сыйдырасы
Упкынга тиң шагыйрь дөньясын...

*25 февраль, 2016*

***

Тән саулыгы – иң зур байлык,
Җанга, аңга тән кирәк!
Тән җавабы – җан газабы,
Аңламасаң иртәрәк...

*26 февраль, 2016*

***

Күк Тәңренең юмарт иләгеннән
Энҗе-мәрҗән ява, килде кыш,
Кызыл түбәләрдә боз бию -
Фламенкодан откан чагылыш.
Гранадада боз яңгыры ява,
Ак мәрҗәннәр җирдән тәгәри,
Тып-тын һава, ап-ак пәрдә булып,
Боз яңгыры. Яумый, сибәли...
Сары елмаюлы әфлисунга
Энҗе-мәрҗән алка элгәндәй.
...Безнең карлар. Безне сагынып килгән.
Безнең сагынуны сизгәндәй...

*26 февраль, 2016*

***

И тырышты Күкләр, сипте мәрҗән,
Яз туена әзерләнү мәле...
...Әйтерсең лә ялап алды кояш
Юлдан тәгәрәгән мәрҗәннәрне...

*27 февраль, 2016*

***

...Сине, диңгез, мин бер аңлармынмы,
җан иясе кебек син миңа,
дулкын яллы атлар табынидай,
бер ыргыла диңгез, бер тына...
күңел-байтал сиңа тартыла...

Кыя-ташка бәрелеп чәчрисең дә,
комлы ярга килеп ятасың,
серле дөнья, серле дәрья – диңгез,
сер сандыгың кемгә ачарсың?
комлы ярда ниләр сызасың?

Синең тиңең, диңгез – текә таулар,
ә мин сиңа сәер бер балык,
яр буенда каләм тибрәтүче,
аңлап түгел, тоеп, сокланып...
төпсез төпкелләрдә югалып...

Сине, диңгез,
мин бер аңлармын да,
җан
 җиһанда тамчы булганда,
Син һәм Җиһан – Мин һәм Синең кебек,
мин аңлармын ...күктә туганда...
...бер тамчыдан хасил туганнар...

*28 февраль, 2016*

***

Уңда диңгез, сулда – таулар,
Ә каршыда – кыя-таш,
Каурый болытларны этеп,
Чәчләрдән сыйпый кояш.
Шаулатып искән җилләрне
Ташларга бәйли кыя.
Диңгез тыныч. Табигать тә
Язга тамгалар куя...
Андалусия җире бу,
Урта диңгез буйлары...
Диңгез тыныч. Бәргәләнә
моң канатлы уйларым...

*28 февраль, 2016*

***

Ак болытлар йөзә кичке күктә –
Дулкын-дулкын диңгез күңеле,
Болыт булып, хисләр күккә ашкан,
Диңгез күңеленнән түгелеп...

*28 февраль, 2016*

***

Испан иле. Калаонда. Диңгез.
Күз алдында чынга ашкан рәсем!
Черемоя, авакада* пешкән
тауларында
        җәннәт биләмәсе...
Үтеп керә һәрбер күзәнәккә
Һава тәме – тәндә, җанда, аңда,
Юк бәйләми, били бар дөньяны,
Биләве дә озын – таңнан-таңга.
Шундый халәт – гүя сүзләр эри,
Сүзләр эри, тиеп хисләр өне.
Ә ничек соң сүрелмәслек итим,
Бу дөньяга гашыйк халәтемне?!

*февраль, 2016*

** Черемоя, авокадо – җиләк-җимеш исемнәре*

***

Тау каюлы затлы касә,
Бу – Гранада яклары!
Кояш нурыннан чолганган
Әфлисун йомгаклары...

Тау битендә затлы зәйтүн –
Зәйтүн исе бертоташ.
Сыланып зәйтүн маена
Шәфәкъкә чумган кояш...

*29 февраль, 2016*

***

Рәссамнарга монда эшләр җиңел,
Кая күз салсаң да – әзер рәсем.
Хәтта рәсем ясап тору артык,
...Күз алдына бер рам күтәрәсе.

*29 февраль, 2016*

***

Андалусия җирендә
Һәр үзән – гүзәл бакча,
Әйтерсең лә, безнең юллар,
Сузыла җәннәт аша.

Бу мәһаббәт рәт-рәт таулар,
Ак калфак, ак кәләпүш,
Зәйтүн исеннән хисләнеп
Шигырь язам, мин, сәрхүш.

Сервантеска илһам биргән
Чибәр кызлар кайда, сез?
Монда илһам чыганагы
...әфлисун, таулар, диңгез.

*1 март 2016*

***

Мин биредә башка бер дөньяда,
Гаҗәпмени канат тагылу.
Әмма күңел әллә кайдан тоя -
Бу дөньяның күге – сагыну...

Җимешләре җәннәт бакчасыннан,
Гаҗәп түгел рәхәт табылу.
Җимеше дә өйне хәтерләтә,
Бу дөньяның җире – сагыну...

Мин биредә җилдән дә көч җыям,
Тәңре кушып, иңә савыгу...
Тән-җан-аңга – сихәт, әмма никтер,
Бу дөньяның җиле – сагыну...

Диңгез-таулар иле, оҗмах дөнья,
Бу уйлану, түгел табыну.
Ягымлы да диңгез, әмма никтер,
Дулкын-дулкын кага сагыну...

*Март, 2016*

***

Малага каласы.
Күләгәдән
күчәм күләгәгә.
Көн эссе.
Кала уртасы.
Күгәрчен булып
канат-учын сузган
...Пикассо*.

*3 март, 2016*

** Пабло Пикассо – испан рәссамы*

***

Аннан-моннан чыбык-чабык –
Тузган карга оясы.
Бу рәсемдә – кеше башы,
Ә рәссамы – Пикассо...

*3 март, 2016*

***

Өчпочмак, дүртпочмак, түгәрәк.
Сызыклар, сыныклар – бер рәсем...
Сораулар уята. Эзләтә.
Уйлата. Уята ...Пикассо.

*3 март, 2016*

## Пикассо музеенда

Даһилыкның серен эзлим, күзлим,
Әвеш-тәвеш килгән сызыклардан,
Баш-күз булып яткан шакмаклардан,
Сыннар булып киткән чыбыклардан.
Даһи булсаң – һәр сызганың бөек,
Һәр шакмагың сер саклаган сандык.
Даһилыкны була тамгаларга
бүлеп, шакмакларга салып...
Әмма шакмак илтми даһилыкка,
Шакмак-шакмак – гади күпшакмаклык...
...Даһилыкка дәгъва кылып була,
Чыбыркыны үзеңчә шартлатып!

...Җанлы аккорд булып яңгырый көй,
Һәр нотасы балкып җырлап тора!
Даһи аккорд яңгырашын, тәмен,
Гади ноталардан тоеп кара...

*3 март, 2016*

***

Ялгызлык –
Ут кызуында туңу,
Боз суыгында яну...

*4 март, 2016*

***

Минем эзләр баскыч түгел, ачкыч,
Күк капусын япкан офыкларга,
Минем эзләр ал таңнарга таба,
Офыклардан үтү – оныкларга!..

*4 март, 2016*

***

Җирдә эзләр бер-берсенә ята,
Минем эзләр тиздән тонықланыр,
Минем эзләр баскыч түгел, канат,
Тамгаларны таный белгән оныкларга.

*4 март, 2016*

***

Җирдә юллар кәркеш-җепләр булып
Күңелләргә кадәр бәйләгән...
Өзелсәләр, әйдә өзелсеннәр,
Мин очарга хәзер өйрәнәм!..

*9 март, 2016*

***

Бер аң, бер кан, бер рух –
Нәсел җебе үрелеп килә шул өч кылдан,
Нәсел яши җирдә,
Аерылмаса, бишегендә откан моңнан.

Күкләр көйләвендә -
Нәсел моңы бер күренеш, бер тибрәнеш,
Өзелмәсен бу көй,
Шул көйләрдән Җиһан, шул көйләрдән гареш*...

*9 март, 2016*

** гареш – җиде кат күктәге Тәңре тәхете, көрсие*

***

Дерелдәвек дулкын булып,
Кушылдың син, әти, күккә,
Җан кылларың, хушлашкандай,
Бармакларны сыйпап үтте...

...Инде күптән булган мизгел
Җанга үткән бу тибрәнеш,
Йөрәк хәтеренә сеңгән
Бу хушлашу, бу күренеш...

*9 март, 2016*

## Ерак киләчәккә карап уйлану

Килер вакыт. Безнең чорлар
Калыр тарих төпкелендә.
Һәй, андыгы өстәгеләр,
Бу төпкелдән кем күренә?
Бармы руслар, я татарлар
Сез укыган әсбапларда,
Бармы Этруск*, һуннардан соң
Бер-бер эзләр анналларда?

Бушка түгел бу сораулар
Бүген чәчрәп кайнаганда,
Рус дөньясын, Татар илен
Меңъяшәр дип уйлаганда.
Шул ук уйлар биләгәндер
Кельтларны* да, готларны* да,
Безнең кебек, мәңгелек дип,
Корганнардыр йортларын да.
Кыпчаклар да, болгарлар да,
Яши, дибез, безнең канда,
Әмма кайда ул халыклар,
Исеме кайда, йорты кайда?

Адәм өчен җир мәңгелек,
Җир күзеннән адәм – нокта.
Халык туа, бар кешелек -
Нокта-нокта яктылыктан.
Җирдә халык – бер яктылык,
Җир өчен ул бер күренеш,
Халык булу, яшәп калу -
Сирәкләргә тигән өлеш.
Һәй, андагы өстәгеләр,
Укыйсызмы бу язманы?
Димәк, дөрес яшәгәнбез,
Югалмаган безнең халык.
Татар телен канат итеп,
Нигез итеп Идел-йортны,
Үскән халык, горур халык,
Яңа татар – сәлкеш халкы!..

...Бу бер хыял,
сез күрәсез,
кемнәр сүнгән, кемнәр исән?
Кайнаганда бүген өстә,
Чыгармагыз шуны истән!..

*5 марта, 2016,*

** этруск, кельт (кәлтә), гот (кот) – Европада бүгенге Испания, Италия, Бөекбритания, Франция, Алмания җирләрендә төпләнеп яшәгән халыклар*

***

Каян килә безнең ныклык, кайда моның серләре?
Кайдан дәрман, дәрт, егәрлек, меңъяшәр сеңерләре?
Җыр-моңнары, буй-сыннары, ут уйнату һәр эштә?
Иман, илһам юлы белән иңә булыр гарештән!

*10 март, 2016*

***

*Гаилә-нәсел-өммәт-ыруг-милләт турында уйлану*

Бу бик ачык гыйбарәләр җитте миңа соңлап,
Соң булса да, уң булсын, дип, куям шуны чолгап.
Бер адәм – бер җан, бер кыл ул, тартсаң да өзелә,
Җан-кыллардан үрелгән җеп – өзелмәс гаилә.
Әмма җепләр тиз таркала, җепләр бигрәк нәзек,
Меңләп җептән үрелгән бау – таркалмас бер нәсел.
Меңләп баудан ишсәң канат – булыр тымат өммәт,
Өммәт булып үсү өчен өммәт рухы кирәк.
Меңләп канат ишелгәндә булып бер моң-рухта,
Хасил була тымат аркан – тәңгәл бер ыругка.
Меңләп аркан кушылганда туа бер ил-куәт,
Һәм нигезе, ил йөзеге – көчле, дәртле милләт.

*10 март, 2016*

*Халык – бер дәүләт кешеләре*
*Милләт – бер ил кешеләре*
*Гаилә-нәсел-өммәт-ыруг-милләт*

***

Бу дөньяда  бөтен нәрсә үзгәрүчән,
Бу дөньяда бөтен нәрсә үзгәрүдә,
Бу дөньяда һәрнәрсәнең башланмышы,
Дәвамы бар, һәм ахыры, дөнья очы.

Һәммә нәрсә фани, фани барча дөнья,
Бакыйлыкка дәгъва кылган меңнәр кайда?
Тик мәңгелек алда булыр, булган элек...
Бу парадокс – дөнья фани ...һәм мәңгелек!

*11 март, 2016*

***

Бу матурлык – хисләр кайнатырлык,
Пумалаңны ман да – сыз гына,
Бу табигать күзләр, күзәнәкләр аша
зиһенеңне били, сызыла.
Пикассоны шуннан аңлыйм кебек,
Хисләр кайный, таша, чуала,
Матурлыктан шашып, Пикассо да,
Ватык йөзләр, сыннар сырлаган.
Табигатьтән сүр катына качып,
Иҗат иткән Сальвадор Дали*,
Кабатланмас тере матурлыктан
Ваз кичүгә җиткән ул даһи.

Иҗатларын аңлыйм димим, белмим,
Әмма керәм рәссам хәленә,-
Табигатьне киндер эчләренә
Сыйдырырлык Рәссам бер генә...

*11 март, 2016*

** Сальвадор Дали – испан рәссамы, сюрреалист*

## Гранада – Биләр

Үттең күңелгә син, алдың хушымны,
Йөрәк тибеше дә сиңа кушылды,
Гранада, тойдыңмы минем хисләрне,
Әзрәк баедымы күңел дәфтәрең?
Үттең күңелгә син, алдың хушымны...

Гранада, Гранада, гүзәл бер кала,
Синдә бер кунак мин, күңелем башкада,
Йөртәм йөрәктә мин Чишмә, Биләрне,
Күңел канатларым – татар көйләре.
Гранада, Гранада, гүзәл бер кала...

Гранада матур да, йөрәк нигәдер,
Болыт күргәндә дә ныграк тибәдер,
Хуҗа тавыннанмы килгән болытлар,
Чишмә суларымы сеңгән болытка?
Бүген аеруча моңсу, нигәдер...

Татар көйләре шул күңел түрендә,
Гранада синдә дә Биләр күңелдә,
Минем моңсулык ул килә тирәннән,
Кайда булганда да күңел Биләрдә,
Татар көйләре шул күңел түрендә...

Йөрәк һич онытмас, бергә, янәшә,
Гранада, Биләр һәм Чишмә гел яшәр,
Якын миңа хәзер халкы һәм иле,
Гранада, Гранада, Гранада җире...
Гранада, Биләр һәм Чишмә янәшә...

*13 март, 2016*

## Фәнир бабай утары

Фәнир бабай утары дип, керде алан күңелгә,
Монда аның, утар булып, хыяллары үрелгән.
...Бер утар гына түгел бу,
бу – табигать кочагы.
Җәйге урман. Җиләкләрнең
учка сикергән чагы!
Дөнья яме бер аланда, урман каюлы алан,
Чут та чут кошлар сайравы аланны чолгап алган.
Аллы-гөлле күбәләкләр, аллы-гөлле чәчкәләр,
Күбәләк көе күңелдә, кулда – тулы касәләр.
Касәләрдән ташып тора җан рәхәте – чын кымыз,
Әйдә, дустым, тарт тальяның, син бит көйгә дә хирыс!
Бал кортлары беззелдәве дәрт өсти күңелләргә,
Кәрәзле балы абзыйның ягыла шигырьләргә.
Балның төсе бер үк – алтын, әмма – тәме! Тәм – үзгә!
Кояш нурын тутыралар бал кортлары кәрәзгә!
Яшел урман, балыклы күл, гөлләрнең кәләш чагы...
Бу – аланга әверелгән Фәнир бабай кочагы...

*16 март, 2016*

***

Черки белән адәм аермасы –
Елга белән диңгез арасы.
Адәм белән Кеше аермасы –
Җир белән күкләр арасы...

*23 март, 2016*

***

Барселона. Сагунт урамында
яшим әле, шунда гомер сөрәм.
Сагунт атамасын сүтеп-җыеп,
Гун бабайлар эзен, сүзен күрәм.
...Сагун-сёгун-цигун – ци гун, чи* гун -
Яшәү көче тулы, димәк, кәттә!
Испан-япон-кытай үз иткән сүз -
Күз алдында – егәр һун егете...

*21 март, август 2016*

** чи-ци – яшәү энергиясе*

***

Мин Монҗуик түбәсендә.
Унда – кояш. Аста – диңгез.
Кулны сузсам – кул болытка тигән кебек.
Җил сул яктан. Куенга ук үтә,
мин Иделдән, сине таныйм, дигән кебек...

*25 март, 2016*

***

Күңел күген кара болыт
каплаган  чакта, кинәт,
Яшен яшьнәп, күк күкрәде,
Яуды яңгыр иркенләп.
Күңел күге аязланды,
Тынды күкрәү, ялт-йолтлар,
Каурый-каләм булып кына
Йөзә каурый болытлар.
Давылдан соң татлы тынлык
Күңелем төпкелендә,
Сибәли шигырь яңгыры
...Салават күпереннән.

*26 март, 2016*

## Тукайны уйлап...

Тукайны аңлау өчен дә, Тукайга килү өчен,
Җитмәс гомер, аңлау килер буыннар аша күчеп.
Йөз еллык соклanулар да, йөз ел сүнмәгән бәхәс,
Бу иҗатның серен эзләү кыза гына, һич сүнмәс!

Тукай миндә – мин туганчы. Тукайлы минем бәгырь.
Тик шулай да, аңладым, дип, әйтергә җитмәс гомер.
Иҗатына, моңга манып, җан җылысын салганга,
Тукайны аңлау тәңгәлдер ...үз-үзеңне аңлауга...

*27 март, 2016*

***

Һәркемгә мәгълүм –
Тавык йомырка сала.
Әле, йомырка салган саен,
аны зур эшкә санап,
кеткелдәп тә ала.

Бөркет тә йомырка сала.
Ә бөркет йомырка сала, дип,
Бармы ишеткәнең?
Шуны уйлап кара.
...Бөркет – бала чыгара!..

*4 апрель, 2016*

***

Сине күккә күтәрергә күтәрелгән дип уйлаган куллар
җеназа күтәрергә күтәрелгән куллар булмагае...)

*6 апрель, 2016*

***

Рух тәнемдә күңел хуҗа,
Рух күгендә күңел – бөркет!
Таш кыялар аста, нокта-нокта,
Оча бөркет, канатларын җилпеп...

*Апрель, 2016*

***

... Барселона таң алдыннан –
чут-чут килеп, кошлар сайрый.
Ара-тирә былбыл моңы,-
Мин ул көйне меңнән таныйм!

Барселона сандугачы
Өзеп-өзеп тезә моңын...
Әллә шулай тоеламы
Тартылганга күңелем кылы?

...Кистереп көйли сандугач,
Стаккатога ята моңнар,
Өздереп сайрап җибәрсә,
Ишелер күк таш диварлар.

Юк, сайрамый, өзгәләнә,
Туктап, туктап, кисеп моңны...
...Ә Аккошта* сандугачлар
Сузып сайрый, тоташ моңлы...

*16 май, 2016*

** Аккошта – Аккош күлендә*

***

Пикассоның даһилыгын
Тырышам мин аңларга.
Мадрид булсын, Барселона,
Эзлим Малагаларда.
Бер җирдә – төрле сыннары,
Бер җирдә – сөяркәсе,
Бер җирдә – буяганнары,
Бер җирдә – рәссам үзе.
Күгәрченен аңлыйм кебек,
Әйе, дуслык – кул-канат,
Төсле-төсле ямаулыклар,
Шакмак-почмактан ир-ат...
Нидер бардыр нигезендә,
И мактый ла бер белгеч,
Мин дә телим сокланырга -
Ачылмый күңел-күргеч.
Өлгермәгән күңелдәме,
Күзләрдәме бар сәбәп,
Пикассо белән аңлашу
Кала бирә, үрсәләп...

*Март-май, 2016*

***

Кем ул даһи? Кем ул гади?
Кайчан даһи? Ничек даһи?
Бу – табышмак, ачылмас сер,
Зиһен теше үтмәс вәхи*...

Бу сорау килеп кадалды
Пикассоның музеенда,
Пикассоның даһилыгын
Мин ишетәм уңнан, сулдан,
Даһи Пабло, Пабло – Даһи!
Малаганың даһи улы!
Һәр сызганы Пикассоның
Алла кушып, Алла кулы...
Кайтып-кайтып карыйм-эзлим,
Юк, әлегә әзер түгел,
Нәрсәнедер аңлап җитми,
Кабул итми минем күңел...
Ахры, күзләр монда көчсез,
Аң үтмәгән күренешләр,
Минем күңел кылларына
Моң салмаган тибрәнешләр...
Бәхәсләшмим, мин – уйланам,
Рәссам Пабло Пикассоның
Чишәр өчен бөек серен –
Аңлар өчен даһилыгын.
Бер карасаң, Тәңре кушып,
Меңләп рәссам – меңләп талант,
Ә шулардан кайсы даһи?
Рәсемнәрдән әйтеп кара...

...Һәркем гади, һәркем даһи,
Гадилектә – даһилык бар,
Сынап кара, даһилыктан
гадилеккә ябык юллар.
Бер ачылгач даһи булып,
Нәрсә сызса даһи кулы -
күпноктамы, я түгәрәк -
без беләбез – мәгънә тулы...
Даһи сызган бер шакмакта
меңләп мәгънә – меңләп дөнья,
Гади нокта куйганда да
ул ноктаны даһи куя...
...Гадилектән даһилыкка
Бармы юллар, бармы үсеш?
Әллә инде бу очракмы,
Көтелмәгән шартсыз күчеш?
...Яза торгач, аңладым бит
ничек даһи булалганны:
Уйландырса, сискәндерсә,
Һәрбер ноктаң, һәр сызганың...)

*3 март–24 май, 2016*

** Алла тарафыннан пәйгамбәр күңеленә салынган фикер, хәбәр…*

***

Пикассоның бакчасында
Меңләп иҗат җимеше,
Үз туксаны туксан мәллә,
Җитмешме үз җитмеше?
Бакчасында җимешләре -
Берсеннән-берсе сәер,
Әллә инде гүзәллекнең
Киресен* тапкан бахыр.
Мин дә, син дә – бармы, юкмы,-
Баш катырмый, уйланып,
Сыза, буйый – ни һушында –
Үзенә үзе халык.
Әллә шулмы бакыйлык та,
Әллә шулмы даһилык?
Аңлашуның аръягында
Аңны каплаган болыт...

Мин килешмим,
Мин – биреләм,
Әйе – даһи. Мин – җүләр.
Пикассо – даһи түгел дип
Китералмыйм дәлилләр.

*Март-май, 2016*

** хакыйкатьнең киресе дә хакыйкать (Н.Бор). Шуңа ишарә*

***

*И. Хановка* багышлау*

Ул – яктылык тудыручы иде,
Чаткы чыгаручы чакма ташы,
Җиргә сөрелмәгән, Прометейдай –
Җирдә тудырылган, күкләр кушып.
Таш кыясы – аның бcombinationалары,
Чылбырлары – хыял-теләкләре,
Төрле юлдан килгән затларның да
Бер тибешле итте йөрәкләрен.

Күккә юллар салды бәгыреннән,
Тәңре йорты – уртак оя, диеп,
Үз гомерен учак итте безгә,
Ханов Илдар – татар Прометее...

*4 март-5 июнь, 2016*

** Күренекле татар рәссамы, экстросенс*

***

Офыклардан мине күзләмәгез,
Мин күренмәм таныш сукмалардан,
Фани дөнья арбасында мин – юк,
Юллар инде бакыйлыкка таба...
Күк капусы бер ачыла, беләм,
Шул мизгелне күрә белү кирәк.
Бу – шул мизгел, күк капусы – ачык!
Аръякларга гомер күчте, кинәт...
Күкләр ачык, килде яңа халәт,
Сәер халәт – җан иректә, ирек!
Тән дә исән! Җан – тән белән,
Аучы-ханнан аерылмас лачын кебек!
Күңел – тулпар, канатларын җилпи,
Яңа җилләр, яңа дөнья тоя!
...Фикер-хисләр-нәфес арбаларын
Яңабаштан сүтеп сипләп җыям.
...Юк, көтмәгез, элеккеге Җәүдәт
күренер дип, кайтыр бер тәгәрәп,
Бу гомердә – инде башка тормыш,
Үткән тормыш – тулы бер түгәрәк.
...Мин югалмам кинәт, эзләр кала,
Тамга булып, йөргән юлларымда.
Сөләйман бар, яши Әдип Әлмир -
...Мин дә шунда – шигырь-җырларымда.
Югалмадым – дөнья алмашынды,
Дөнья башка, мин дә – үзгәрәк,
Әйтерсең лә кичә курчак идем,
Бүген инде очам... күбәләк...
Мин югалмам, мин булырмын тамга –
Юл чатында киңәш көткәннәргә,
Мин килермен җылы җилләр булып
Моңга манма күңел-җилкәннәргә.

Дөньяң алмашулар – янә туу,
Тән тиресен салу гына түгел,
Әйтерсең лә, тышчаларын ташлап
Яңа халәт тоеп оча күңел...

Алмагачлар шуны кичерәдер,
Шул ук халәт, шул ук аның сере,
Гади бөреләрдән чәчкә-яфрак
Яралганда, язгы җилләр өреп.

... Күңел тышчалары катлы-катлы,
Үрелгән дә хисләр, бәйләнгән дә...
Сүтеп кара, гомер үргән хисләр
Бәгырь җепләренә әйләнгәндә.
Бәгырьләргә тия аерылу,
Җан-бәгырьнең җепселләрен тетә,
Иң авыры... Иң авыры... Белмим,
Иң авыры, бәлки, алда көтә...

...Күзләмәгез мине офыклардан,
Мин күренмәм таныш сукмалардан,
Фани дөнья арбасында мин – юк,
Юллар инде бакыйлыкка таба...

*Январь-май, 2016*

***

Өлгергән күңел ул – ачыла бер нурдан,
Бер нурда – мең сүзлек бәрәкәт*...
Нурларга ялганган әрнүле җаннарга
Юл таба сихәтле бәрәкә*...

*4 март – 4 июнь, 2016*

** бәрәкәт – файда, уңыш (рус.: изобилие, добро, благодать)*
*** бәрәкә – Тәңре шәфкате (рус.: благость)*

***

Диңгез бүген назлы бер кош сыман,
Вак-вак дулкын – каурый-канатлары,
Иркәләнә ярга килеп ятып
Сыйпый-сыйпый комлы бармакларны.

Ком өстендә калган безнең эзләр
безнең хисләр тулы язма сыман,
Ак каурыйлы канат очы белән
Диңгез шуны сыйпап ала сыман.

Күңлем күге бүген шундый биек,
Дөнья үзе күңел үзәгендә.
Яшькелт-зәңгәр диңгез гүя бер кош,
Канат кагып оча күңелемдә...

*5 июнь, 2016*

## Венерага

Син бит диңгез кызы, син – диңгездән,
Урта диңгез синең тамырларда,
Син диңгезгә кайттың!
- Сәлам, диңгез!
Диңгез шавы канда – гасырлардан!

Сине көткән диңгез, шуңа ярсу,
Шуңа бәрә шашып дулкыннары.
Син һәм диңгез. Дәрья һәм тамчысы.
Син тумыштан, ахры, диңгез яры.
Син тумыштан диңгез алиһәсе,
Күңелең синең шуңа диңгездәдер.
Диңгез жене кагылгандыр сиңа,
Диңгез җиле сине әйдәгәндер.

Диңгез белән синең күрешүең
Гүзәл мизгел! Күрәм, диңгез разый!
Син диңгездә – янә туган сабый,
Диңгез кочагында диңгез кызы...

*5 июнь, 2016*

***

Карт алмагач кәүсәсендә
Яшь үсенте күреп,
Бу – исәрлек галәмәте
дигән идем.
Шигъри хискә биреп ирек,
шул алмагач халәтендә
түгелме соң инде
бүген үзем?

*7 июнь, 2016*

***

Бар бөекләр татарда да рәссамнардан,
Китап тулыр, һич ким булмас даһилардан...
Бар Урманче*, Ханов Ильдар – и ул Тәңре рәхмәте!
Минем өчен татар Пикассосы – Дефак Рәхмәти**...

*1 август, 2016*

** Бакый Урманче – татар рәссамы, мәшһүр сынчы*
*** Дефак Рәхмәти – татар рәссамы, язучы, эзотерик*

***

Шаккатырды янә бүген Пикассо давылы.
Яшь кызлардан үргән ахырзаман өермәсе.
Туксан яшьлек күзләр и дулаган, и сыланган,
И сырлаган кайтып-кайтып бот тирәсен...

*6 август, 2016*

***

Айга бер күрешү – тән көтә, җан көтә,
Хәл кертә табиплар тамчылап.
Кайталсам кирегә, йөгертер идем гел
Үземне, жәлләми камчылап.

Айга бер күрешү – уйлану, сөйләшү,
Богаулар бик авыр ачыла,
Бәгырьне чолгаган җепләрдән арынам,
Үземне жәлләми камчылап.

Айга бер күрешү, көн – тоташ өметтән,
Көт, тәнем, канатлан, түз, чыда!
Зиһенне, акылны яңартам, төзәтәм,
Үземне жәлләми камчылап!
Айга бер күрешү...

*9 август, 2016*

***

*цикл*
*Ни чәчсәң – шуны урырсың...*

Бу – әйтелгән кырга карап,
Күңел дә шул иген кыры.
...Алабута чәчкән кырдан
Интегәбез... бодай урып...

*

Күңел ул үзе – шигырьдән,
Канатлы ул тумыштан.
Йолкып-тартып каурыйларын
Өйрәтәбез ...тормышка.

*

Хыял таулары күңелдә,
Моң үзәкле гел, тоташ...
Кай арада моң – зар була,
Ә хыяллар – кыя-таш?

*

Тар күңелне үлчим дисәң,
Иркен булыр энә күзе...
Киң күңелгә – дөнья сыя,
Киң күңелдә – кояш үзе!...

*Май-август, 2016*

***

Ситҗес яңгырыннан җанга рәхәт.
Төнге яңгыр яшен утларында
бәреп-бәреп юа
зәңгәрлеген, эңгерлеген көннең,
сафландырып күңелләрне.

...шунысы рәхәт, кап-кара төн,
ява яңгыр, элми генә күккә
алы-гөлле күперләрен.
Күк ял итсен, шәһәр дә ял итсен,
безгә дә ял булыр ул төсләрдән.
...Аллы-гөлле төсләр
тансык ул Иделдә
балкыганда күк йөзендә
сорылыкны этеп күңелләрдән...

Шатландырмый, гәрчә, күнегәсең,
көндез соры, төссез тирә-юньнәр
кемдер кыйбла иткән ул төсләрдән...
Әйтерсең лә шәһәр төсе суырыла
аләмнәргә төсләр булып ятыр өчен...
Әйдә, яңгыр, кой чиләкләп, агыл күктән,
Тансык яңгыр, көткән яңгыр, күрсәт көчең!
Чәпә тотып урамнарны изүеннән!
Яңгыр һавасында йокылар да татлы, тирән,
Бер-бер артлы төсле төшләр керә
яфракларда шыбыр-шыбыр тамчы биюеннән.

*10 август, 2016*

***

*Мин диңгез дулкыны, түз, елга...*
*Сөләйман (1996)*

Мин диңгез дулкыны, диңгездә,
Арындым сыкранган елгадан,
Ярлары арынгач, үрә-тау дулкыннан,
Җайланыр бер заман елга да.
Мин диңгез дулкыны, диңгездә!..

Ни рәхәт бу диңгез кочагы,
Очынып кыяда чәчрәүләр!
Ярларга бәрелеп, болганып балчыкта,
Ни гомер интеккәнмен, җүләр!
Ни рәхәт бу диңгез кочагы!..

Ни рәхәт диңгездә, юк чикләр,
Бер төпкә, бер күккә ыргылу!
Көмештән киенеп, нурларга күмелеп
Ярларга ятуы сузылып!
Ни рәхәт, диңгездә юк чикләр!..

И елга, җайланыр агышың,
Арындың алҗыткан дулкыннан,
Янәдән елганы үз итәр, сыйпалып,
Дерелдәп тибрәнгән дулкыннар.
И елга, җайланыр агышың!..

Мин диңгез дулкыны – диңгездә,
Син дә юл тотасың – диңгезгә,
Үткәнгә салават, күрешербез җайлап,
Ә диңгез үз итәр, тигезләр...
Мин гади бер дулкын диңгездә.

Мин гади бер ...диңгез дулкыны...

*Январь-август, 2016*

***

...Башка дөнья. Гомер дәвам итә,
Өзелмәгән әле өйгә юллар,
Өзелмәгән әле ризыкларым,
Өзелмәгән кайтып очрашулар...
Хәтер җепселләре әле исән,
Исән әле, исән хатирәләр.
...Әмма җанның ефәк өрфиясен
Тибрәндереп исә яңа җилләр.
Башка дөнья, башка халәт, уйлар,
Башка сыман һәр күз салган тараф.
Көн касәсе тулы кояш нуры,
Ай диңгезгә төнен көмеш сала...
Әллә мохит, әллә вакыт сәбәп,
Күчте күңел гүя чүрәсенә.
Җайлана җан, кинәнә тән, зиһен -
Нечкә күңел күге-даирәсендә.
Бу күкләрдән әле кайтып була,
Әле исән кайту җепселләре,
Әмма инде очларында бушлык
Мин бәйләнгән байтак җепселләрнең...

...Ә кайтулар бардыр...
Әти, бабайлар да
кочалардыр, бәлки, җилләр булып,
Ничек белик, ничек тойык шуны,
юллар артык нечкә, булмый сыеп...
җилләр дә бик нечкә,
теге дөньяларны булмый тоеп...

...Мин яшәгән дөньялардан әле кайтып була...

*Январь-16 август, 2016*

## Тумыштан яраттым дөньяны...

Тумыштан яраттым дөньяны.
Дөньяга сыенып, ачылып,
сөенеп – яшәдем...
Килде көн, җәелгән кочакта
...җил генә икәнен шәйләдем.
Күз нурын каплады яшьләрем,
Аңладым,
бу – минсез дөньяда яшәвем...

Сүрелде учаклар, ябылды кочаклар,
Татыдым әчесен-төчесен
    мин эчке дөньямда яшәүнең...
Һәм... житте ниһаять,
миңа да ачылды
бу гади хакыйкать -
бу фани дөньяның
...минсез дә гөрләтеп яшәве...

...Алыш-биреш тигезләште, тәмам!
Хуш, бишектән күккә илткән дөньям!
Синдә мин дә,
миндә син дә – юк!
Каршымда яңа көн, яңа күк!
Бу дөнья җаныма һуш дөнья,
Күңелем сизенә, мин тоям,
Шәҗәрәм – канатым,
Бу минем халәтем, бу – оям...

Хуш, дөньям,
мин китәм, юк – ...кайтам...
Хуш, дөньям, мин сине яраттым, яратам.
Ачыла өрфия дөньялар,
Җан оча, канатлар җайлана...

...Берничә йомгаклык җан җебе
тетелгән бу тәндә, эрләнгән –
Очлары тирәндә, шәҗәрә-тамырга
кан белән, моң белән бәйләнгән...

Дөньядан дөньяга салына эзләрем,
Дөньядан дөньяга бар юллар,
Ул юллар күренә
тик ...нечкә күңелгә,
һичкайчан өзелмәс ул кыллар...

...Бакыйлык хикмәте йомгакта,
Дөньялар тезелә җан-җепкә.
Тетелгән җанымнан җеп эрлим,
Җеп очын беркетәм ...бишеккә...

*

...Әни, гафу, ачуланма, зинһар,
Яза диеп әллә нинди сүзләр,
Тузга язмаганны казып, сызып,
Җанны өзеп, уйдырмалар эзләп...
Ачуланма әни, кайту өчен сәбәп,
Бик нечкәреп югалмаудан дәва -
Ул син – әни, ул бары син, әни,
Башка җепләр үз очларын табар...

Ә без икәү, җепнең ике очы,
Җеп сузыла бәгырьләрне ялгап...
Шул җепләрдән гомер-орчыкка
Әти белән чолгагансыз йомгак...
Әти очы инде күренми дә,
Маңгай күзен тоныклата еллар.
Без тоябыз, фәрештәләр булып
саклый безне әти сузган кыллар...

...Гомер-орчык тынды беравыкка...
Кулларымда тулы бер йомгак.
Чират хәзер инде оныкларда -
Җирдә йомгак чолгау, сүтеп-ялгап.

...Гафу, әни, ачуланма, улың
тузга язмаганны тезә диеп,
Безнең җаннар инде мәңге бергә,
Җеп очлары төенләнде бергә килеп.
Әле җирне тоям табан белән,
Канатларны кагам җайлап кына,
Туганлыкның нечкә җепселләрен
югалтмыйм, дип,
барлап-барлап кына.

...әмма инде яңа дөнья алда,
хушлашасы, нечкәргәнче тәмам...
Мин югалмам мине көткәннәрдән,
Күрешүгә тамга юллар салам...

*1 апрель-19 август, 2016*

***

*“Бик матур ап-ак кар ява, тиздән каз өмәсе...”*
*Әни белән телефоннан сөйләшкәндә*

“Ап-ак карлар явып үтте, улым,
Авыл шундый матур, ап-ак, хәйран!..
Каз өмәсе тиздән, шау-гөр килеп...”
...Әйе, истә, әни, – җылы бәйрәм.

...Кыйгак-кыйгак... бездә каз өмәсе...
Оча мамык, өмә! – гөрли халык...
Түшкә-түшкә яткан йорт казыннан
Булмый микән бер-бер гыйбрәт алып...

...Ап-ак карлар, ап-ак дөнья – матур,
Сорылыкка җәймә булып – бер ямь...
Салкын шәрәлектә кар да – бәхет...
Әмма күбрәк ак киемнән килә ...матәм.

*3 ноябрь, 2016, Ситҗес*

***

Йөгерек дулкыннар  диңгездә,
Йөгерек дулкыннар күңелдә,
Күбеккә чолганган дулкыннар
күңелдә бәйләнгән Иделгә.

Диңгездә йөгерә ак дулкын,
Иделдә җемелди ап-ак кар.
Яз җитәр, ташкынга әйләнеп,
диңгезгә кушылыр ак карлар.

Ак дулкын, ап-ак кар – бер дөнья,
Бу аклык бик якын күңелгә,
Әйтерсең, ак карлар Иделдән,
чук булып дулкынга чигелә...

*26 январь, 2017*

***

Ситҗес. Диңгез. Ширингито кафесы.
Чапирон. Пескадо. Гамбас –
Тәмле ризык. Барысы.
Сере гади. Исемендә җисеме.
Ризыкка да тәм өсти ул
Ширинбану исеме.

*9.01.2017*

***

Диңгез кайда да диңгез дә,
Бу диңгез башкачарак,
Дулкын шавын үрәм җанга
Хис-таракларга тарап.

Диңгезләр ул кайда да бер,
Тик монда башкачарак,
Бер ел гомер хискә дулкын -
Юк, сыйпамый, актара.

Диңгез кайда да диңгезме?
Юк, бусы башкачарак,
Хәзер диңгез инде миндә,
Дулкыннар җанга кага.

Диңгез кайда да диңгездер,
Ә монда башкачарак,
Башка бер дөнья чиге бу,
Әлегә чит-ят тараф...

*10 январь, 2017*

## Күзәтүләр

*Дулкыннар зәңгәр, яшел дә,*
*Хәтта соры, кайчакта...*
*Әмма нинди булсалар да,*
*Һәрчак ап-ак калфактан.*

Без беләбез, гореф-гадәт, килеш-килбәт
Мохит аша табигатьтән безгә иңә.
Кызык бит ул, ак калфактан безнең кызлар,
Диңгездәге дулкыннар да калфак кигән.

Тарих сөйли, ватаныбыз Урта диңгез,
Безнең халык, төрки-татар шуннан килгән.
Милләт йөзен билгеләгән ак калфак та
Шул фаразга бер ишарә түгел микән?

*22 январь, 2017 3:38*

## Әтигә*

Әти кулларында күккә очуларым,
Җилкәсендә тойган рәхәтлек,
Истән чыкмас хисләр – күңел канатлары,
Әти, сиңа мин мең рәхмәтле!
Бәхет кайда дисәң, әти кочагында,
Җылы карашында әтинең,
Мәхәббәтле дөнья, мәрхәмәтле дөнья -
Син төзегән дөнья, әтием.

Кушымта:
Гомер узган саен, якын миңа әти,
Уйларымда аңа эндәшәм,
Тормышымда минем ышанычлы терәк,
Әти сүзе, әти киңәше.

Күз яшьләрең безгә күрсәтмисең, әти,
Сыкранмыйсың, әти, язмышка,
Сиңа сыенганда җил-давыллар тына,
Ямь өстәлә сыман тормышка.
Йөрәгеңдә, әти, синең дөнья гаме,
Матурлыкка ачык күңелең,
Синең белән, әти, без канатлы кошлар,
Мәңге өзелмәсен гомерең.

Кушымта.

*27 январь, 2017*

**Эльмир Низамов көе*

***

Сагынабыз, ...сагынам, дип, ихлас,
Абый, диеп әйткән сүзләрдер,
...Сагынам, дип өстәп куелганы,
Күңелгә үк үтте, нигәдер...

Сагынам дип, хәтта яратам, дип,
Әйтелә ул, күңелең тулып,
Әлегәчә шулай иде, никтер,
Башкачарак булды бу юлы...

Тартма-тартма шырпы яндырып та
Ут эленми кайчак учакка,
Әмма ялкын ялмап алсын өчен,
Чаткысы да җитә, кайчакта...

*29 январь, 2017*

***

Аяк богаулану әле коллык түгел,
Канат кага күңел, җан тыныч,
Чылбыр-богау канга күчә калса,
Бусы – коллык, бусы – куркыныч...

*30 январь, 2017*

***

Мурта иле малын – балын алучылар
өрдерәләр аңа башта төтен.
...Чит-ят гадәт, чит-ят көйләр, мохит
шул ук төтен халык-милләт өчен.

*8 февраль, 2017*

***

Килде аңлау. Шул ук моһит, шул бер дөнья –
Бервакытта – җәннәт тә ул, тәмуг та ул.
Дөньям минем, дисең, җәннәт булган икән,
Саулык бетеп, әверелгәч, тәмугка ул.

*10 февраль, 2017*

***

Тән һәм җаным. Сез тибрәлгән бишек
Бәгырь җепләреннән үрелгән.
Мин үзем дә шул бишектә үсәм,
Күңелем белән күккә үреләм.

*10 февраль, 2017*

***

Өч өлештән хасил бәгырь үзе,
Ул өч өлеш – ул сүр, кот һәм мән,
Безнең бәгырь җирдән күккә кадәр
җан җепләре белән тегелгән.

*17 февраль, 2017*

***

Ситжес. Бәйрәм. Уен-көлке –
Бәхет каюлы мәйдан!
Урамнардан халык түгел,
Шатлык агыла сыман.

*26 февраль, 2017*

**Эчтәлек**

«Урал таулары...» *(Мюнхен, Германия)* ....................................3
«Барс илендә, Барс җирендә...» *(Барселона, Испания)* ....................4
«Дөньяның төрлелегенә...» *(Барселона)* ....................................5
«Җир шарында...» *(Барселона)* ....................................6
Тел дөньясы *(Каталуния мәйданы, Барселона)* ....................................7
«Бер карыйсың...» *(Барселона)* ....................................8
«Хәтер җебе тоташ...» *(Барселона)* ....................................9
«Кемгә дә бәйләнмим...» *(Барселона-Истанбул, Испания-Төркия)* ..10
Татарга *(Барселона)* ....................................11
«Бер карыйсың...» *(Барселона)* ....................................12
«Күңел-диңгез төпкелендә...» *(Барселона)* ....................................13
«Диңгез буе. Дулкын уйный...» *(Барселона)* ....................................14
«Адәмдә өч дөнья – береккән өч фәза...» *(Барселона)* ....................15
«Күзне йомсам – Аккош күле...» *(Барселона)* ....................................16
«Каталуния илендә...» *(Барселона)* ....................................17
«Иртәгә футбол уены...» *(Барселона)* ....................................18
«Барселона, Барселона, Ай йөзә төнге күктә...» *(Барселона)*......19
«Барселона, Барселона, Нәрсәң артык Казаннан?..» *(Барселона)*.20
«Уңнан-сулдан машиналар...» *(Барселона)* ....................................21
«Барселона бүген моңсу...» *(Барселона)* ....................................22
«Учак янында гәпләшү...» *(Барселона)* ....................................23
«Готик квартал дигәннәре...» *(Барселона)* ....................................24
«Гренаданың Испан моңсулыгы...» *(Гранада)* ....................................25
Фламенко *(Гранада)* ....................................26
«Бу – Гранада, күпне күргән шәһәр...» *(Гранада)* ....................................27
Альгамбра *(Гранада)*....................................28
«Гарәптән калган дисәм дә...» *(Айбальсин бистәсе, Гранада)* ........30
«Без бергә икәү, шуңадыр, җан тыныч...» *(Армийя, Гранада)* ...31
«Альборрея, Альбохарра...» *(Гранада)* ....................................32
«Дөнья якты, әмма – кысан!» *(Армийя, Гранада)* ....................................33
«Шәһәр ап-ак...» *(Гранада)* ....................................34
«Әни белән телефоннан сөйләшеп алгач...» *(Армийя, Гранада)*....35
«Ап-ак тешле Невада пычкысы...» *(Гранада)*....................................36
«Кулда каләм, ак бит кәгазь...» *(Гранада)*....................................37
«Чал Альгамбра итәгендә...» *(Гранада)* ....................................38
«Моннан карап – Казан тимерчелек...» *(Гранада)* ....................................39

«Лорка йорты...» *(Ф. Гарсиа Лорка паркы, Гранада)* ........................40
«Тән саулыгы...» *(Гранада)* ....................................................41
«Күк Тәңренең юмарт иләгеннән...» *(Гранада)*.............................42
«И тырышты Күкләр...» *(Гранада)* ............................................43
«...Сине, диңгез, мин бер аңлармынмы...» *(Калаонда)* ...................44
«Уңда диңгез, сулда – таулар...» *(Калаонда)*................................45
«Ак болытлар йөзә кичке күктә...» *(Калаонда)*..............................46
«Испан иле. Калаонда. Диңгез...» *(Калаонда)*. ..............................47
«Тау каюлы затлы касә...» *(Андалусия)* ......................................48
«Рәссамнарга монда эшләр җиңел...» *(Калаонда тирәсе)* ...............49
«Андалусия җирендә...» *(Андалусия)* .........................................50
«Мин биредә башка бер дөньяда...» *(Гранада-Малага-Барселона)* 51
«Малага каласы...» *(Малага)* ....................................................52
«Аннан-моннан чыбык-чабык...» *(Малага)* ...................................53
«Өчпочмак, дүртпочмак, түгәрәк...» *(Малага)* .............................54
Пикассо музеенда *(Малага)* .....................................................55
«Ялгызлык...» *(Малага)* ..........................................................56
«Минем эзләр баскыч түгел, ачкыч...» *(Малага)* ..........................57
«Җирдә эзләр бер-берсенә ята...» *(Малага)* .................................58
«Җирдә юллар кәркеш-җепләр булып...» *(Барселона)* ....................59
«Бер аң, бер кан, бер рух...» *(Барселона)*....................................60
«Дерелдәвек дулкын булып...» *(Барселона)* .................................61
Ерак киләчәккә карап уйлану
*(Согунт (Ци-Һун)урамы, 5, Барселона)* ........................................62
«Каян килә безнең ныклык...» *(Барселона)* ..................................64
«Гаилә-нәсел-өммәт-ыруг-милләт
турында уйлану...» *(Барселона)* ...............................................65
«Бу дөньяда бөтен нәрсә үзгәрүчән...» *(Барселона)* ......................66
«Бу матурлык – хисләр кайнатырлык...» *(Барселона)* ....................67
Гранада – Биләр *(Гранада-Барселона)* .........................................68
Фәнир бабай утары *(Барселона)*.................................................69
«Черки белән адәм аермасы...» *(Барселона)*.................................70
«Барселона. Сагунт урамында...» *(Барселона)*...............................71
«Мин Монҗуик түбәсендә...» *(Монҗуик тавында, Барселона)* ......72
«Күңел күген кара болыт...» *(Барселона)* ....................................73
Тукайны уйлап *(Барселона)* .....................................................74
«Һәркемгә мәгълүм...» *(Барселона)*............................................75
«Сине күккә күтәрергә...» *(Барселона)* .......................................76

«Рух тәнемдә күңел хуҗа...» *(Барселона)* ......................................77
«... Барселона таң алдыннан...» *(Барселона)* ..................................78
«Пикассоның даһилыгын...» *(Малага-Барселона)*............................79
«Кем ул даһи? Кем ул гади?..» *(Малага-Барселона)*.........................80
«Пикассоның бакчасында...» *(Малага)* ..........................................82
«Ул – яктылык тудыручы иде...» *(Малага-Барселона-Ситҗес)* ......83
«Офыклардан мине күзләмәгез...» *(Барселона)* ...............................84
«Өлгергән күңел ул...» *(Малага-Барселона-Ситҗес)*...........................86
«Диңгез бүген назлы бер кош сыман...» *(Ситҗес)* ..........................87
Венерага *(Ситҗес)* ...........................................................................88
«Карт алмагач кәүсәсендә...» *(Ситҗес)* ...........................................89
«Бар бөекләр татарда да рәссамнардан...» *(Ситҗес)*.........................90
«Шаккатырды янә бүген...» *(махсус күргәзмәдән соң, Барселона)* . .91
«Айга бер күрешү – тән көтә, җан көтә...» *(Ситҗес)* .......................92
«Бу – әйтелгән кырга карап...» *(Барселона-Ситҗес)* .........................93
«Ситҗес яңгырыннан җанга рәхәт...» *(Ситҗес)* ...............................94
«Мин диңгез дулкыны, диңгездә...» *(Барселона-Ситҗес)*.................95
«...Башка дөнья. Гомер дәвам итә...» *(Барселона-Ситҗес)*...............96
Тумыштан яраттым дөньяны... *(Барселона-Ситҗес)* .........................97
«Бик матур ап-ак кар ява...» *(Ситҗес)* ..........................................100
«Йөгерек дулкыннар диңгездә...» *(Ситҗес)*.......................................101
«Ситҗес. Диңгез. Ширингито кафесы...» *(Ситҗес)* .........................102
«Диңгез кайда да диңгез дә...» *(Ситҗес)*..........................................103
Күзәтүләр *(Ситҗес)* .........................................................................104
Әтигә *(Ситҗес)* ...............................................................................105
«Сагынабыз, ...сагынам, дип, ихлас...» *(Ситҗес)* ...............................106
«Аяк богаулану әле коллык түгел...» *(Ситҗес)* ..................................107
«Мурта иле малын – балын алучылар...» ..........................................108
«Килде аңлау...» *(Ситҗес)*..................................................................109
«Тән һәм җаным...» *(Ситҗес)* ............................................................110
«Өч өлештән хасил бәгырь үзе...» *(Ситҗес)* ......................................111
«Ситжес. Бәйрәм. Уен-көлке...» *(Ситҗеста карнавал)* ......................112

Литературно-художественное издание

**СУЛЕЙМАН**
**(Сулейманов Джавдет Шевкетович)**
***Из Каталунской тетради***

Казань. Издательство Академии наук
Республики Татарстан. 2017

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**СӨЛӘЙМАН**
**(Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улы)**
***Каталун дәфтәреннән***

Басарга кул куелды 14.06.2017.
Гарнитура «Times New Roman».
Офсет кәгазь. Форматы 60х84 1/32. Басма табагы 3,625.
Тиражы 3000 д. Заказ 14.06/17-1

ТР Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан, Бауман ур., 20